**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Иске Үтәмеш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге составына керүче Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктында (ларында) гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**21 октябрь 2022 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Үтәмеш, Югары Чегодай, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, шулай ук мобилизацияләнгән гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Иске Үтәмеш, Югары Чегодай, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктларында урам утларын ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- су башняларын, скважиналарны, Иске Үтәмеш авылында «Мәликә», «Атау», «Абзалетдин», Югары Чегодай авылында «Әчеле», Иске Сережкино авылы торак пунктында чишмәләрне ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, койманы төзү, ремонтлау һәм буяу, су башнясын буяу, павильонны төзү, тышлау, каты өслекле юл урнаштыру, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документациясе өчен түләү) Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктларында скважиналарны һәм каптажны лицензияләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.
- Югары Чегодай, Иске Үтәмеш, Урманасты Үтәмеш, Иске Сережкино торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү,

карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, агрегатлар сатып алу, хезмәтләргә түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;

- Иске Үтәмеш авылындагы Тынычлык урамындагы күперне ремонтлау һәм югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Мингулов